**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**О внесении изменений в отдельные указы Президента Республики Татарстан**

1. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 11 июля 1997 года № УП-359 «Об учреждении Международной Арбузовской премии в области фосфорорганической химии» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 18 августа 2006 года № УП-313, от 8 апреля 2017 года № УП-297, указами Раиса Республики Татарстан от 11 июля 2023 года № 484, от 5 августа 2024 года № 592 и от 6 марта 2025 года № 183) следующие изменения:

а) в пункте 1 слова «два года» заменить словами «три года, начиная с 2025 года»;

б) в Положении о Международной Арбузовской премии в области фосфорорганической химии:

в абзаце первом пункта 2 слова «два года» заменить словами «три года, начиная с 2025 года,»;

в пункте 3 слова «500 тысяч рублей» заменить словами «один миллион рублей».

2. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 1 ноября 2014 года № УП-1014 «Об учреждении Международной премии имени А.Н. Туполева за выдающийся вклад в области инженерных наук» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 22 февраля 2016 года № УП-200, от 9 июня 2017 года № УП-488, от 13 апреля 2018 года № УП-309, от 14 июля 2021 года № УП-579, от 24 декабря 2021 года № УП-991 и Указом Раиса Республики Татарстан от 11 июля 2023 года № 484) следующие изменения:

а) в пункте 1 слова «два года» заменить словами «три года, начиная с 2026 года»;

б) в Положении о Международной премии имени А.Н. Туполева за выдающийся вклад в области инженерных наук:

в пункте 2 слова «два года, начиная с 2015 года» заменить словами «три года, начиная с 2026 года»;

пункт 6 изложить в следующей редакции:

«6. Лицам, удостоенным Международной премии, присваивается звание «Лауреат Международной премии имени А.Н. Туполева за выдающийся

вклад в области инженерных наук», вручаются диплом, медаль и осуществляется выплата денежных средств в размере одного миллиона рублей.»;

пункт 10 изложить в следующей редакции:

«10. Вручение диплома и медали производится Раисом Республики Татарстан или уполномоченным им лицом.»;

в) в Положении о Комитете по присуждению Международной премии имени А.Н. Туполева за выдающийся вклад в области инженерных наук:

подпункт «в» пункта 4 изложить в следующей редакции:

«в) оформление наградных документов, организация вручения диплома и медали;»;

пункт 9 изложить в следующей редакции:

«9. Руководство Комитетом осуществляется председателем Комитета, который планирует работу Комитета, назначает и ведет заседания Комитета. В период отсутствия председателя Комитета его обязанности по поручению председателя Комитета исполняет один из его заместителей.»;

г) в составе Комитета по присуждению Международной премии имени А.Н. Туполева за выдающийся вклад в области инженерных наук (далее – Комитет):

вывести из состава Комитета Д.Н. Баракоса, В.П. Гапонцева, Н.В. Савицких, М.Х. Салахова, М. Шмидта;

ввести в состав Комитета:

Александрова Анатолия Александровича – президента федерального государственного автономного образовательного учреждения высшего образования «Московский государственный технический университет имени Н.Э. Баумана (национальный исследовательский университет)» (по согласованию);

Бобрышева Александра Петровича – управляющего директора акционерного общества «Туполев» (по согласованию);

Гарипова Алексея Олеговича – заместителя генерального директора – главного конструктора опытно-конструкторского бюро акционерного общества «Казанский вертолетный завод» (по согласованию);

Долженкова Николая Николаевича – директора дивизиона беспилотной авиации – генерального конструктора беспилотных авиационных систем акционерного общества «Уральский завод гражданской авиации» (по согласованию);

Дуба Алексея Владимировича – первого заместителя генерального директора акционерного общества «Росатом Наука» (по согласованию);

Жиркова Евгения Николаевича – генерального директора акционерного общества «Зеленодольское проектно-конструкторское бюро» (по согласованию);

Иноземцева Александра Александровича – управляющего директора акционерного общества «ОДК-Авиадвигатель» (по согласованию);

Минниханова Рифката Нургалиевича – президента государственного научного бюджетного учреждения «Академия наук Республики Татарстан», утвердив его заместителем председателя Комитета (по согласованию);

Рудского Андрея Ивановича – ректора федерального государственного автономного образовательного учреждения высшего образования «Санкт-Петербургский политехнический университет Петра Великого» (по согласованию);

Шкадаревича Алексея Петровича – директора научно-производственного унитарного предприятия «Научно-технический центр «ЛЭМТ» БелОМО» открытого акционерного общества «Минский механический завод имени С.И. Вавилова – управляющая компания холдинга «БелОМО» (по согласованию);

изложить в следующей редакции наименования должностей членов Комитета:

Ю.Ф. Гортышова – «советник ректора федерального государственного бюджетного образовательного учреждения высшего образования «Казанский национальный исследовательский технический университет им. А.Н. Туполева – КАИ», секретарь Комитета (по согласованию)»;

А.А. Калачева – «директор федерального государственного бюджетного учреждения науки «Федеральный исследовательский центр «Казанский научный центр Российской академии наук» (по согласованию)».

3. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 25 июля 2020 года № УП-453 «Об учреждении Международной премии имени В.В. Марковникова за выдающийся вклад в области органической химии» (с изменениями, внесенными Указом Президента Республики Татарстан от 28 июня 2022 года № УП-441, указами Раиса Республики Татарстан от 10 февраля 2024 года № 104 и от 5 августа 2024 года № 592) следующие изменения:

а) в пункте 1 слова «два года, начиная с 2020 года» заменить словами «три года, начиная с 2027 года»;

б) в Положении о Международной премии имени В.В. Марковникова за выдающийся вклад в области органической химии:

в пункте 2 слова «два года» заменить словами «три года, начиная с 2027 года,»;

в пункте 6 слова «500 тысяч рублей» заменить словами «одного миллиона рублей»;

в) в составе Комитета по присуждению Международной премии имени В.В. Марковникова за выдающийся вклад в области органической химии изложить наименование должности А.О. Терентьева в следующей редакции: «директор федерального государственного бюджетного учреждения науки Института органической химии им. Н.Д. Зелинского Российской академии наук, член-корреспондент Российской академии наук (по согласованию)».

4. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Раис Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН · ОБЩИЙ ОТДЕЛ · ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
28 мая 2025 года
№ 420

| УКАЗ<br>РАИСА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>РӘИСЕ<br>УКАЗЫ |
| --- | --- |

**Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Фосфорорганик химия өлкәсендә халыкара Арбузов премиясен гамәлгә кую турында» 1997 елның 11 июлендәге ПУ-359 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 18 августындагы ПУ-313 номерлы, 2017 елның 8 апрелендәге ПУ-297 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 11 июлендәге 484 номерлы, 2024 елның 5 августындагы 592 номерлы һәм 2025 елның 6 мартындагы 183 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1 пунктта «ике елга» сүзләрен «2025 елдан башлап, өч елга» сүзләренә алмаштырырга;

б) Фосфорорганик химия өлкәсендә халыкара Арбузов премиясе турында нигезләмәдә:

2 пунктның беренче абзацында «ике елга» сүзләрен «2025 елдан башлап, өч елга» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «500 мең сум» сүзләрен «бер миллион сум» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Инженерлык фәннәре өлкәсендә зур өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге Халыкара премияне гамәлгә кую турында» 2014 елның 1 ноябрендәге ПУ-1014 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 22 февралендәге ПУ-200 номерлы, 2017 елның 9 июнендәге ПУ-488 номерлы, 2018 елның 13 апрелендәге ПУ-309 номерлы, 2021 елның 14 июлендәге ПУ-579 номерлы, 2021 елның 24 декабрендәге ПУ-991 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 11 июлендәге 484 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1 пунктта «ике елга» сүзләрен «2026 елдан башлап, өч елга» сүзләренә алмаштырырга;

б) Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премия турындагы нигезләмәдә:

2 пунктта «2015 елдан башлап, ике елга» сүзләрен «2026 елдан башлап, өч елга» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Халыкара премиягә лаек булган затларга «Инженерлык фәннәре өлкәсендә А.Н. Туполев исемендәге халыкара премия лауреаты» дигән исем, диплом, медаль һәм бер миллион сум күләмендә акча бирелә.»;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Дипломны, медальне һәм акчаны Татарстан Республикасы Рәисе яисә ул вәкаләт биргән зат тапшыра.»;

в) Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премияне бирү комитеты турында нигезләмәдә:

4 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) бүләкләү документларын рәсмиләштерү, диплом һәм медаль тапшыруны оештыру;»;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Комитет белән Комитет рәисе җитәкчелек итә, ул Комитет эшен планлаштыра, Комитет утырышларын билгели һәм алып бара. Комитет рәисе эш урынында булмаган вакытта, Комитет рәисе вазыйфаларын аның кушуы буенча урынбасарларының берсе башкара.»;

г) Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премияне бирү комитеты (алга таба – Комитет) составында:

Комитет составыннан Д.Н. Баракосны, В.П. Гапонцевны, Н.В. Савицкихны, М.Х. Сәлаховны, М. Шмидтны чыгарырга;

Комитет составына кертергә:

Александров Анатолий Александровичны – «Н.Э. Бауман исемендәге Мәскәү дәүләт техник университеты (илкүләм тикшеренү университеты)» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе президентын (килешү буенча);

Бобрышев Александр Петровичны – «Туполев» акционер җәмгыяте идарәче директорын (килешү буенча);

Гарипов Алексей Олеговичны – «Казан вертолет заводы» акционер җәмгыяте генераль директоры урынбасары – тәҗрибә-конструкторлык бюросы баш конструкторын (килешү буенча);

Долженков Николай Николаевичны – «Урал граждан авиациясе заводы» акционер җәмгыятенең пилотсыз авиация дивизионы директоры – пилотсыз авиация системалары генераль конструкторын (килешү буенча);

Дуб Алексей Владимировичны – «Росатом Фән» акционер җәмгыяте генераль директорының беренче урынбасарын (килешү буенча);

Жирков Евгений Николаевичны – «Зеленодольск проект-конструкторлык бюросы» акционер җәмгыяте генераль директорын (килешү буенча);

Иноземцев Александр Александровичны – «ОДК-Авиадвигатель» акционер җәмгыяте идарәче директорын (килешү буенча);

Комитет рәисе урынбасары итеп раслап, Миңнеханов Рифкать Нургали улын – «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесе президентын (килешү буенча);

Рудской Андрей Ивановичны – «Бөек Петр исемендәге Санкт-Петербург политехника университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректорын (килешү буенча);

Шкадаревич Алексей Петровичны – «С.И. Вавилов исемендәге Минск механика заводы – «БелОМО» холдингы идарәче компаниясе» ачык акционер җәмгыятенең «БелОМО «ЛЭМТ» фәнни-техник үзәге» фәнни-җитештерү унитар предприятиесе директорын (килешү буенча);

Комитет әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Ю.Ф. Гортышовның – «А.Н. Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры киңәшчесе, Комитет секретаре (килешү буенча)»;

А.А. Калачевның – «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе директоры (килешү буенча)».

3. Татарстан Республикасы Президентының «Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен В.В. Марковников исемендәге халыкара премияне гамәлгә кую турында» 2020 елның 25 июлендәге ПУ-453 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2022 елның 28 июнендәге ПУ-441 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Рәисенең 2024 елның 10 февралендәге 104 номерлы һәм 2024 елның 5 августындагы 592 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1 пунктта «2020 елдан башлап, ике елга» сүзләрен «2027 елдан башлап, өч елга» сүзләренә алмаштырырга;

б) Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен В.В. Марковников исемендәге халыкара премия турында нигезләмәдә:

2 пунктта «ике елга» сүзләрен «2027 елдан башлап, өч елга» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта «500 мең сум» сүзләрен «бер миллион сум» сүзләренә алмаштырырга;

в) Органик химия өлкәсенә күренекле өлеш керткән өчен В.В. Марковников исемендәге халыкара премияне бирү комитеты составында А.О. Терентьевның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Россия фәннәр академиясенең Н.Д. Зелинский исемендәге Органик химия институты федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе директоры, Россия фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы (килешү буенча)».

4. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2025 ел, 28 май
№ 420